**СОВЕТ
БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул. Московская, 2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ БИТАМАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В.

тел./факс 8(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17 июнь 2024 е.** **№ 92**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 05 июнендәге 173 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге, Россия Федерациясенең аерым хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 06 июнендәге маендагы 173 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре»нә (Советның 14.09.2021 №31, 20.02.2024 №84 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең II бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 9.1 пункт белән тулыландырырга:

«9.1. Сосновский балтырганының үсешен таратмау максатыннан, юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр), оешу-хокукый формаларына карамастан, шулай ук физик затлар, үзләренең милкендәге яки файдалануындагы җир кишәрлекләрендә Сосновский балтырганының юк итү буенча чараларны үткәрергә тиеш.»;

1.2. Кагыйдәләрнең II бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт белән тулыландырырга:

«11.1. Автомобиль юлларының юл яны полосасында яки аларга якын урнашкан сервис объектлары (кибетләр, кафелар, кунакханәләр, АЗСлар, СТО, ял итү мәйданчыклары һ.б.) өчен бүлеп бирелгән территорияләрне тәртипләп тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы тарафыннан башкарыла.»;

1.3. III бүлекнең атамасын «автотранспорт чараларын кыска вакытлы саклау» сүзләреннән соң, «, юл сервисы объектлары " сүзләре белән тулыландырырга.»

1.4. «Җир кишәрлекләрен карап тоту» бүлегенең 35 нче пунктында «тимер юллар,» сүзен алып ташларга;

1.5. III бүлекнең «җир участокларын карап тоту» бүлекчәсенең 35 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 15 абзац белән тулыландырырга:
физик затлар һәм юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) үз милкендә яки файдалануында булган җир участокларында Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар үткәрү.»;

1.6. 37 нче бүлекнең 6 нчы абзацында “юлларны карап тоту” III бүлегенең “һәм тимер юл" сүзләрен алып ташларга;

1.7. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту» бүлегенең 66 нчы пунктында «(тимер юл)» сүзе төшереп калдырырга;

1.8. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту» бүлекчәсенең 67 пунктында «(тимер юл)» сүзе төшереп калдырырга;

1.9. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту» бүлекчәсенең 68 пунктында «(тимер юл)» сүзен алып ташларга.

1.10. III бүлекне түбәндәге эчтәлектәге бүлекчә белән тулыландырырга:

"Сервис объектларының карап тоту”.

92.1. Сервис объектлары территорияләрен карап тоту мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан башкарыла.

92.2. Юл буендагы сервис объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:
- уңайлы хәрәкәт өчен каты катлам;
- территорияне яктырту, архитектур-декоратив яктырту;
- урнаштыру һәм тоту таләпләрен үтәүче бәдрәф кабиналары;
- чүп өчен савытлар һәм кечкенә контейнерлар;
- яшелләндерү (газоннар, чәчәклекләр) һәм яшелләндерү участокларын саклау элементлары (кечкенә коймалар).

92.3. Сервис объектларын урнаштыру һәм аларга якын территорияләрне карп тоту таләпләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:
- сервис объектларына керү-чыгу юллары кучу-тизлек полосалары белән җиһазландырылырга тиеш;
- сервис объектларының кучеш-тизлек полосалары һәм территорияләре тышкы яктырту белән җиһазландырылырга тиеш;
- юл хәрәкәтенә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгына керү-чыгу урыннарында су агып китү җайланмалары куелырга тиеш (керү-чыгу урыннары астында су үткәрү торбалары салынырга тиеш), һәм алар төп юлдан су агып китү системасы белән тоташкан булырга тиеш;
- хәрәкәт һәм керү-чыгу урыннарына хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгының озынча авышлыгы юлның каршы ягына юнәлтелергә тиеш. Түгәрәкләнү радиуслары чикләрендә ул 20‰тәшкил итәргә тиеш.
- керү-чыгу урыннарыны һәм мәйданчык төп автомобиль юлы белән тигез ныклылыкта һәм камилләштерелгән капламга ия булырга тиеш;
- юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары ГОСТ Р 52289-2019 “Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл знакларын, билгеләрне, светофорларны, юл коймаларын һәм юнәлеш бирүче җайланмаларны куллану кагыйдәләре" таләпләренә

ярашлы рәвештә;

- сервис объекты территориясендә эксплуатация һәм карап тоту процессындагы кимчелекләрне бетерү ГОСТ Р 59292-2021 “Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Җәйге карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары” һәм ГОСТ Р 59434-2021 “Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кышкы карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» таләпләренә ярашлы рәвештә башкарылырга тиеш;

- функциональ билгеләнеш буенча юл хәрәкәтенә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясе, шул исәптән, санитар-гигиена зонасына да ия булырга тиеш;

- тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан каралган булырга һәм бирелгән техник шартларга ярашлы файдаланылырга тиеш;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 24.11.1995 ел, 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, юл буендагы сервис объектларының транспорт чаралары тукталышында инвалидлар идарә иткән транспорт чараларын бушлай парковкалау өчен урыннар бүлеп бирелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» на: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе урынбасары,
Олы Битаман авыл җирлеге башлыгы урынбасары Г.Н.Ибраһимова